ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 4-05-07; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

от «11» ноябрь 2022 ел — № 21

Отарка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" гы 30.04.2021 ел, № 22 карарына үзгәрешләр кертү турында

« Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының 30.04.2021 ел, № 22 карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пункттан һәм 12 пунктның 2 абзацыннан «муниципаль программаларның структур элементлары»сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 2 пункттан «муниципаль программаларның структур элементлары»сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 12 пункты 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "ташламалардан файдаланучылар саны һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны һәм бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы 5 еллык чорда.»

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының (mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче / И.И.Фазылов /